ГЛАВА МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН», МЭР ГОРОДА ЛЕНИНОГОРСКА

«ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШЛЫГЫ ЛЕНИНОГОРСК ШӘҺӘРЕ МЭРЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **К А Р А Р**

28.04.2020 г.Лениногорск № 50

«Гаилә» торак районы составындагы территорияне ызанлау проектын планлаштыру һәм аның составындагы территорияне ызанлау проектын карау буенча гавами тыңлаулар уздыру турында

Халыкның муниципаль хокукый актлар проектлары буенча фикер алышуда катнашу хокукын үтәү, җир кишәрлекләре хокук ияләренең уңай тормыш шартларын, хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 маддәсе, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 ст., 46 ст. нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан «Гаилә» торак районы составындагы территорияне планлаштыру һәм аның составындагы территорияне ызанлау проектын карау буенча «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2020 елның 21 апрелендәге 526 номерлы карары нигезендә әзерләнгән гавами тыңлаулар үткәрелә башлау турында хәбәр итәргә.

**2.** Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан «Гаилә» торак районы составында территорияне планлаштыру һәм аның составындагы территорияне ызанлау проектын карау буенча гавами тыңлауларны 2020 елның 05 маеннан 05 июненә кадәр уздырырга.

3. Татарстан Республикасы, Лениногорск шәһәре, Тукай урамы, 7, 2 нче кат адресы буенча «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлегенең мәгълүмат

стендларында территорияне планлаштыру проекты һәм аның составындагы территорияне межалау проекты экспозициясен ачарга.

Проект экспозициясе белән танышу вакытын дүшәмбедән җомгага кадәр 9.00 сәгатьтән 11.00 сәгатькә кадәр һәм 14.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр билгеләргә.

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлегенә экспозиция эше барышында экспозициягә килүчеләргә ачык тыңлауларда каралырга тиешле проект турында консультация бирүне оештырырга.

4. 2020 елның 05 маена кадәр территорияне планлаштыру һәм ызанлау проектын түбәндәге рәсми сайтта http://Leninogorsk.tatarstan.ru «Шәһәр төзелеше. Планлаштыру проектлары" урнаштырырга.

**5.** Гавами тыңлауларда катнашучыларга планлаштыру проектына һәм аның составында межалау проектына кагылышлы тәкъдимнәрен һәм искәрмәләрен 2020 елның 28 апреленнән 29 маена кадәр Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе исеменә язма рәвештә, Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Интернет-кабул итү бүлмәсендә түбәндәге адрес http://leninogorsk.tatarstan.ru буенча кертергә яки ачык тыңлауларда катнашучылар җыелышын уздыру барышында телдән.

6. Татарстан Республикасы, Лениногорск шәһәре, Тукай урамы, 7, 2 нче кат, 1 нче кабинет адресы буенча «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге бинасында халык тыңлауларында катнашучылар җыелышын билгеләргә.

7. Лениногорск муниципаль районының http://Leninogorsk.tatarstan.ru адресы буенча рәсми сайтында, шулай ук «Лениногорские вести» газетасында гавами тыңлаулар башлану турында әлеге хәбәрне бастырып чыгарырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше башлыгы В.Н. Маркеловага йөкләргә.

Р.Г. Хөсәенов

В. Н. Маркелова
5-28-28